# Мәктәп елларын искә төшереп

Әнием, Галимова Илсөяр Вәлиәхмәт кызы, 1935 елда Кукмара районы Кенәбаш авылында туган. Ул бары дүрт ел белем алган. Әниемнең мәктәп еллары турында сөйләгән истәлекләре белән бүлешәсем килә.

"Мин мәктәпкә 1942 елда, 8 яшем тулгач, беренче сыйныфка бардым. Әти сугышта, әнинең бер узенә 5 бала һәм әби.Мәктәп бинасы агачтан эшләнгән, ике зур сыйныф бүлмәсе бар. Түшәме биек, бүлмәләре иркен. Мичкә утын ягып җылыталар, шулай да артык җылы булмый иде.

Авыл зур булмаса да, без ул вакытта бер сыйныфта егермедән алып утызга кадәр бала булганбыздыр. Төгәл санын хәтерләмим. Рус теле, математика, әлифба, табигать белеме, физик культура дәресләрен укыганнар истә калган. Беренче сыйныфка баргач, язарга хәзерге кебек дәфтәр, ручкалар юк. Без хәрефләрне күмер белән агач кисәкләренә, тактага язып өйрәндек. Соңыннан сабын кәгазенә яза башладык. Суга корым салып болгатып кара ясыйбыз. Каз канатын очлы итеп кисеп, каләм ясап, шул карага манып яздык. Әле ул кара язганда җәелә, матур итеп язып булмый. Сыйныфта такта, акбур бар иде үзе. "2", "3", "4", "5" дип сан белән билге кую юк, укытучы бары тик безнең эшләр астына "яхшы", "уртача", "начар" дигән сүзләр яза иде.

Сыйныфта тәртип булгандыр, чөнки укытучыларыбыз таләпчән, усал иделәр. Иң шаян малайлар да алардан курка иде.

Тәнәфесләрдә уйныйбыз, малайларның биек мәктәп түбәсенә менеп, шуннан сикереп уйнаган чаклары да булды.

Мәктәптә ашау дигән эйбер юк. Өйдә дә такыр. Ат кузгалагы, черек бәрәнге, алабута җыеп ашадык. Карама, имән агачларының кайрысын җыеп, тартып, он ясап, әниләр кумәч кебек ризык пешерә иде.

Әтиле балаларның киемнәре ару иде. Без, әтисезләр, алама, нык искергән киемнән мәктәпкә йөрдек. Аякта җәй дә, көз дә, кыш та чабата, итек дигән аяк киемен үскәндә күрмәдек. Китапларны чүпрәк букчага салып йөри идек. Өскә

кияргә кием булмаса да, мәктәпкә барасы килмәгән вакытларны хәтерләмим. Кызганыч, бары тик дүрт ел белем алып калдык. Тирә-як авылларда да дүрт еллык кына иде мәктәпләр. Шулай да укытучыларыбыз безгә бик күп мәгълүмат биргән. Мөҗип абый дигән укытучыбыз безгә: "Киләчәктә кешеләр, бик еракта урнашкан илләрдә яшәсәләр дә, берсен-берсе күреп сөйләшерләр,"– дип әйтә иде. "Өйләрдә тартмалар булыр, кешеләр шул тартмалардан төрле сүрәтләр карарлар,"– дип тә сөйли иде. Әйе, укытучыбыз бик күп еллар элек сөйләгән шул могҗизаларны күреп кенә калмадык, бүгенге көндә аларны файдаланып, рәхәтен күреп яшибез,  Аллага шөкер."